ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!

**ОКТЯБРЬ, 2016 нчы ел**

**№2 (20)**






**Бу санда:**

Мәктәбебезгә нур ингән, чөнки өлкәннәр килгән! 2
Бу—кызыклы! 2
Ярышлар гөрләп узды. 3
Якыннан танышыйк! 4
Тиз укырга өйрәтүче 7 кагыйдә 4
Котлыйбыз! 5

## Рәхмәт сезгә, УКЫТУЧЫЛАР !

Хөрмәтле укытучыларыбыз, коллегаларыбыз! Сезне чын күңелдән олы бәйрәмегез белән котлыйбыз! Сезгә җан тынычлыгы, күңел көрлеге, сәламәтлек, хәерле гомерләр телибез. Җылы сүзләребезне, изге теләкләребезне шигъри юллар аша җиткерәсебез килә.

*Укучы... Нинди матур бу сүз.*
*Укытучы- хезмәт иясе.*
*Якын кешеләрем, сезнең алда,*
*Килә безнең башны иясе.*

*Укытучы кеше гыйлем иясе дә,*
*Әни кебек үзе мөлаем.*
*Зирәк сүзен кызганмаган*
*Бу дөньяда бар соң кем тагын?*


*Укытучы мәңге онытылмый*
*Хөрмәт-сөю һәрчак саклана.*
*Укучылар оясына очкан коштай*
*Вакыт табып сагынып кайталар.*

*Укытучым, җанга якын кешем*
*Кылдыгыз сез безгә изгелек.*
*Гамәл, киңәшегез үзегезгә*
*Бирсен иде бары игелек!*



# Мәктәбебезгә нур иңгән, чөнки өлкәннәр килгән!






Мәктәбебездә өлкәннәр көне уңаеннан шактый гына эшләр башкарылды. Һәр атнаның җомга көнендә тимурчылык отряды членнары ялгыз әбибабайларга булыштылар. Рәсемнәр, стенгазеталар, конкурслар үткәрелде. Укучыларыбыз ветеран укытучыларыбыз белән очрашу барышында бик матур концерт белән чыгыш ясадылар.

Хөрмәтле ветераннар! Шушы олы бәйрәмне барыгызның сау – сәламәт каршылавыгызны, исәнимин булуыгызны, бәхетле яшәвегезне телибез.

Киң күңелегез, юмартлыгыгыз өчен,
Кояш белән Сезне тиңлибез.
Шатлык тулы, куанычлы,
Озын гомер Сезгә телибез.

**Гафурова Алия**







## Бу - кызыклы !



**Даниядәге «куб-мәктәп». Әлеге мәктәпләр тыштан гына матур булып тоелмый, ә уку процессына да яңача карый.**

Биредә — һәр укучыга аерым программа каралган,баланың сәләтләре һәм үзенчәлекләре исәпкә алынып эш ителә. Бу мәктәптә 4 нче класстан алып 12 нче класска кадәр балалар белем ала.



### Франциядәге «яшел» мәктәп

Бу мәктәпнең түбәләре һәм ишегаллары яңа үлән белән тулган. Биредә балалар мөмкин кадәр күбрәк урамда, саф һавада булырга тырыша. Һава торышы яхшы булган көннәрдә укулар урамда үтә.

# Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына мәктәпнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Хуҗәхмәтова Гөлчәчәк Сәлиховна җавап бирә.**

-- Балачакта Сез кем булырга теләгән идегез?

- Мин табиб булырга хыялланган идем, ләкин укытучы булганыма бер дә үкенмим.

- Мәктәптә укыган вакытта Сезнен яраткан фәннәрегез?

- Мин бигрәк тә химия, рәсем, җыр һәм биолгия дәресләрен зур түземсезлек белән көтеп ала идем.

- Яраткан укытучыгыз дип кемне саныйсыз?

- Яраткан укытучым математика укытучысы Гөлсинә Мөдәрисова.

- Начар билге алганыгыз булдымы?

- Гомумән, начар билге алганымны хәтерләмим. Бер чиректә сызым фәненнән 3 ле чыканы нык истә калган.

-Нишләп укытучы һөнәрен сайларга булдыгыз?

- Укытучы һөнәрен сайларга балаларны нык яратуым этәргеч булды.

- Сезнең хоббиегыз нинди?

- Мин җырларга һәм рәсем ясарга яратам.

- Укучыларга теләкләрегез?

- Укытучы, тәрбияче буларак теләгем: мәктәпкә, укытучыларга булган хөрмәт артсын, мәгариф системасында тотрыклылык урнашсын.

— Амин, шулай булсын. Эшегездә һәм тормышыгызда һәрчак уңышлар гына юлдаш булсын!

**Әңгәмәне Рәзилә Абдрахманова алып барды**

## *Көлке хикмәте*



********



Бер хатын дус кызына мактана:
-Руль артында булганда мин үземне Аллаһы Тәгалә итеп хис итәм.
-Ник?
-Мин барам, ә янымда утыручы ирем белгән догаларын укый.

*******

Чебурашка Генадан сорый:
– Нишләп синең бер ботинкаң сары, икенчесе кара төстә?
– Белмим, – ди Гена. Өйгә кайтып алыштырмакчы идем, анда да шул ук хәл – берсе кара, икенчесе сары.

# ЯРЫШЛАР гөрләп узды



7 октябрь көнне Фома, Тимерлек, Елаур, Биляр Озеро,Якушкино, Чулпан урта мәктәбе укучылары арасында арасында минифутбол буенча ярыш үтте.

Мәктәбебезнең яшь футболчылары барлык булган көндәшләре белән шәп уен күрсәттеләр һәм җиңү яуладылар. Бу бәйгедә физик тәрбия укытучысы А.К. Замалеевның өлеше бик зур. Ул ихлас елмаю белән балаларны үзенә карата, тыңлата һәм һәр бәйгегә әзерләп, дәртләндереп тора.

Барлык җиңүчеләр грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнде. Тамашачылар – уеннарга килгән кунаклар рәхәтләнеп ял иттеләр, катнашучыларның җанатарлары булдылар.

***Гайшә Таһирова***

## Ни чәчсәң, шуны урырсың

Мәктәп янындагы участокта без кишер, суган, чөгендер, помидор, борыч, кыяр, кәбестә , бәрәнге үстердек. Тырыш хезмәтнең нәтиҗәсе дә бар. 4000 кг кишер, 600 кг. суган, 4000 кг чөгендер, 600 кг. кәбестә саттык, ә үзебез ел әйләнәсендә ашханәдә түләүсез ашыйбыз.

***Гөлшат Гайсина***



## *2017 елда Бердәм дәүләт имтиханы үткәреләсе көннәр билгеле булды.*




Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте 2017 елга Бердәм дәүләт имтиханы расписаниесе раслады.

“2017 елда БДИның вакытыннан алда үтә торган этабы 14 марттан 7 апрельгә кадәр оештырылачак. Ә төп этабы - 26 майдан 30 июньгә кадәр узачак. Узган елдагы кебек үк, БДИ үткәрү расписаниесе проектында “июль дулкыны” каралмаган”. Шул рәвешле, БДИ вакытыннан алда һәм төп этапларда үткәреләчәк.

## Тиз укырга өйрәтүче 7 кагыйдә тәкъдим итәбез.

Тиз укуның, яхшырак истә калдыруның сере бик гади: аның өчен 7 кагыйдәне үзләштерү дә җитә. Малайлар, кызлар игътибар!

**1нче кагыйдә:** текстны, нинди генә авыр булуына да карамастан, бер генә кат укырга кирәк. Укылган өлешкә күзләр белән кире “кайтмагыз”. Кирәк булса, соңыннан — текстның мәгънәсенә төшенгәч тә, тагын бер мәртәбә укып чыгарга мөмкин.

**2 нче кагыйдә:** укуның интеграль алгоритмы буенча уку (УИА)

“Интеграль алгоритм” сүзтезмәсеннән куркып калдыгыз бугай. Бу кагыйдә икенче төрле болайрак яңгырый: китап, журнал, газета битләрен ачканчы, үзеңә нинди мәгълүмат кирәклеген ачыкла! Шуннан соң буталчык укуың УИА программасына буйсыныр.

Игътибарны түбәндәгеләргә юнәлтегез:

-китапның (мәкаләнең)исеме

-авторы

-чыганагы (мәсәлән, мәкалә урын алган газета яки журнал номеры)

күтәрелгән проблема

-бирелгән фактлар

-материаль үзенчәлекләре (жанр, стиль) һәм тәнкыйть (килешү-килешмәү, хуплау-каршы килү)

-алып килгән яңалыгы һәм практикада кулланылышы

**3нче кагыйдә:** текстның төп мәгънәви үзенчәлеген — доминантаны аерып ала белү. Һәрбер текстта алга таба укырга җәлеп итә торган сүзләр була.Шулай ук мәгънә”борылышы”, үзгәрешләр турында “кисәтә” торган сүзләр дә очрый. Бу сигнал — сүзләрне файдаланып, текстагы иң әһәмиятле, иң кирәкле фикерне тотып ала аласыз.

**4нче кагыйдә:** артикуляциясез уку

Әчтән генә укырга өйрәнү өчен, түбәндәге күнегүне кабатларга кирәк: китап яисә газета укыганда, ритмны булдырырга тырышыгыз. Өч бармак ярдәмендә тоткан карандашны, ялгышмаска тырышып, каты өслектәге бер ноктага шакырга кирәк. (Яртылы нота үлчәмен күз алдына китерегез.) Баштарак читен булыр: ритмнан читкә тайпыласың, аннан нәрсә турында укыганың да онытыла. Ләкин 15-20 сәгать күнегүдән соң, ”әйтеп уку” гадәтеннән бөтенләй котылырсыз.

**5нче кагыйдә:** күзләрне вертикаль хәрәкәт иттереп уку.

Моның өчен махсус Шульте таблицасы кирәк. Ул 20 х 20см үлчәмле таблица. 1 дән 25 кә кадәрле саннар 25 шакмакка бутап тутырылган. Барлыгы 8 таблица кулланыла. Сезнең бурыч: 25 секунд эчендә саннарны үсә бару тәртибендә барлап чыгу. Санаганда ялгышмасагыз, күз карашы белән биттәге текстны да укый аласыз диган сүз.

**6нчы кагыйдә:** текстны укыганда, аеруча игътибарлы булу.

Игъбарны башка нәрсәгә юнәлтми генә уку бер дә җиңел түгел. Түбәндәге күнегү ярдәмендә аннан тиз арынып була:

“Бармаклар”. Урындыкка иркенләп утырыгыз. Кулларны кушырып тез өстенә куегыз. Баш бармаклар ирektә калсын. Бер-берсенә кагылдырмыйча гына, аларны хәрәкәт иттерегез. Бөтен игътибар да әнә шуңа юнәлтелергә тиеш. Баштагы ике атнада әлеге күнегүне 5 минут дәвамында ясасагыз, аннары 10-15 минутка кадәр озайтырга була.

**7нче кагыйдә:** һәрчак хәтерне күнектереп тору.

Укылган әйберләр 1-2 көн узуга ук башыңнан чыгып очкач, күп һәм тиз укуыңның мәгънәсе бар микән? Шуңа күрә хәтерне күнектерү бик мөһим. Онытмагыз: 7 кагыйдә дә бер-берсе белән аерылгысыз.

**Педагог—оештыручы**
**Ф.В.Билданова**



## Октябрь аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Галиуллина Әдилә, Мөхәммәтшин Рәзил, Гайсин Марсель, Гилязев Әлфис, Гайсина Вероника, Ситдиков Илнур, Галиуллин Илнар!

Сезне барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , исәнлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

## Хөрмәтле Гөлфия Якуповна !

Сезне чын күңелебездән юбилеегыз белән тәбрик итәбез.

Сезгә шушы бәйрәмегездә теләкләрнең иң изгесен, иң сафын юллыйбыз. Җаныгыздагы йолдызлар балкышын сүндермичә, күңелегездәге яшәүнең алкышын киметмичә, сәламәтлек дәрьясында коенып яшәвегезне телибез.

Укытучым! Котлы булсын туган көнең,
Матур булып атсын таңнарың.
Рәхәт яшә, игелеге кайтсын
Сез укыткан һәрбер баланың.



Тормыш—бәйрәмсез, бәйрәм котлаусыз булмый.

***

Сүз җан җылысы булса, яхшы теләк күңел кояшы ул.

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз

**Дизайнер**: Абдрахманова Рәзилә

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Таһирова Гайшә, Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә